**3. Мин бәхетле туган илемдә**

Алланып таң ата
Газиз җиремдә.
Мин бәхетле, дуслар
Туган илемдә.
Кушымта: Моңнарга күмелсен
Басу-кырлары.
Дөньяга таралсын
Дуслык җырлары.
Килегез яныма,
Якын дусларым.
Күңелне күтәрик,
Дус-танышларым!
Кушымта.
Уйныйбыз, биибез,
Җырлар җырлыйбыз,
Илемә иң якты
Уйлар юллыйбыз!